| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПРИКАЗ** | | **БОЕРЫК** |
|---|---|---|
| **от** 06.05.2013 | Казан ш | **№** 124 к |

**Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә һәм вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре хакында мәгълүмат бирергә тиешле Дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә гражданнар һәм вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы указын, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үз чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2013 елның 22 апрелендәге ПУ-329 номерлы указын үтәү максатларында

б о е р ы к б и р ә м :

1. Кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында (алга таба – Дәүләт комитеты) дәүләт граждан хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә һәм вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре хакында мәгълүмат бирергә тиешле Дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (алга таба – Исемлек) расларга.

2. Кадрлар бүлегенә (Толстая Т.А.):

2.1. Дәүләт комитетының мәнфәгатьле дәүләт граждан хезмәткәрләрен расланган

Исемлек белән таныштырырга;

2.2. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаментына һәм Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру бүлегенә расланган Исемлекне расланган көннән алып өч көнлек чорда тапшырырга һәм, аңа үзгәрешләр кертелгәндә, тәгаенләштерелгән Исемлекне үзгәрешләр кертелгәннән соң бер атна эчендә тапшырырга.

3. Мәгълүматлаштыру бүлегенә расланган Исемлекне Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Дәүләт комитеты сайтында урнаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә һәм вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре хакында мәгълүмат бирергә тиешле Дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 4 номерлы боерыгын көчен югалткан дип танырга.

5. Бу боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны кадрлар бүлеге башлыгы Т.А. Толстаяга йөкләргә.

Рәис М.Р. Зарипов

Кушымта Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 06.05.2013 ел, №124к
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә һәм вазыйфа биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәт рәвешендәге йөкләмәләре хакында мәгълүмат бирергә тиешле Дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:
1.1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары;
1.2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары;
1.3. эшләр идарәчесе;
1.4. идарә башлыгы;
1.5. бүлек башлыгы;
1.6. бүлек башлыгы урынбасары.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясе вазыйфалары:
2.1. рәис ярдәмчесе.

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «белгечләр» категориясе вазыйфалары:
3.1. административ практика бүлеге: әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант;
3.2. гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге: технологик тоташтыру өчен түләүне җайга салу бүлегенең әйдәп баручы консультанты, әйдәп баручы киңәшче, әйдәп баручы консультант.